Иштуган авыл җирлеге составына керүче
Иштуган торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№1

30.11.2024

06.10.2003 елгы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында», 28.07.2004 елгы №45-ТРЗ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән «2025 елда Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлегенең Иштуган авыл җирлеге составына керүче Иштуган торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы» дигән сорау буенча 30.11.2024 елда гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 410 кеше кертелгән, 212 кеше тавыш бирүдә катнашкан. Җыенда катнашучылар саны - 51,71% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

- **«Әйе»** позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 212 кеше тавыш бирде;
- **«Юк»** позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Иштуган авыл җирлеге составына кергән Иштуган авылында халык җыены булып узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре дөрес дип танырга.
2. “2025 елда Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлегенең Иштуган авыл җирлеге составына керүче Иштуган торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы” дигән сорау буенча карарны танырга һәм алынган акчаларны торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Иштуган тимер юл разъезды поселогы - туфрак эшкәртү, комлы нигез салу, вак таштан нигез салу, юл кырыйларын төзү, су үткәрү торбаларын төзекләндерү, эшләр өчен шартнамә буенча түләү) эшләрен башкаруга юнәлдерергә.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/rus/ishtugan бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Саба муниципаль районы Иштуган авыл җирлеге башлыгына җибәрергә

Халык җыенында рәислек итүче
Иштуган авыл җирлеге башлыгы  Д.М.Гайнутдинов

AnyScanner